Татарстан Республикасы
Казан шәһәре Авиатөзелеш районы “134 нче татар-рус урта гомуми белем бирү мәктәбе”
гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесе

| | | |
|---|---|---|
| **Каралды:**<br>МБ утырышы беркетмәсе №1<br>МБ җитәкчесе<br>__________ Зәйнуллина А.Җ.<br>Дата | **Килешенде :**<br>Директор урынбасары<br>_________ Мусина Н.Б.<br>Дата | **Расланды:**<br>Мәктәп директоры<br>_________ Петров А.С.<br>Педагогик совет утырышы беркетмәсе №1<br>Дата |

***Эш программасы***

Фән- татар теле.
Сыйныф, төркем- 8нче “А”, татар төркеме.
Укытучы- Шәйхиева Г.С., татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Гамәлдә куллану вакыты-2015/16 нчы уку елы.

Казан- 2015 -2016 нчы уку елы

## Аңлатма язуы

**Эш программасы статусы**
**8нче сыйныф өчен эш программасы түбәндәге документларга нигезләнеп төзелде:**
1. Россия Федерациясе конституциясе 12.12.1993 (РФ Конституциясенә 30.12.2008 елда №6-ФКЗ, 30.12.2008 елда №7-ФКЗ,21.07.2014 елда №11-ФКЗ белән кергән үзгәрешләр исәпкә алынды.
2. Татарстан Республикасы Конституциясе 6.11.1992(үзгәрешләр һәм әстәмәләр белән)
3. 29.12 2012 нче елда кабул ителгән 273 нче номерлы "Россия Федерациясендә Мәгариф турында" Федераль кануны.
4. 22.07. 2013 нче елда кабул ителгән 68 нче номерлы "Мәгариф турында" Татарстан Республикасы кануны.
5.8.07.1992 нче елда кабул ителгән 1560 – XXII номерлы "Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында" ТР кануны.
6.17.12.2010 елда кабул ителгән 1897 номерлы төп гомуми белем бирүнең(ООО) Федераль дәүләт белем стандарты..
7.ТР Мәгариф министрлыгының 7699/12 номерлы боерыгы, 23.06.2012 ел "Об учебных планах для 1-11 классов школ РТ, реализующих основные образовательные программы начального общего образования и основного общего образования в соответствии с ФГОС общего образования".
8. ТР Мәгариф министрлыгының 9807/12 номерлы хаты, 13.08.2012 ел "О преподавании татарского государственного языка в общеобразовательных учреждениях РТ" һәм №9777/12 номерлы хаты, 13.08.2012 ел "Об изучении татарского языка и литературы в образовательных учреждениях".
9."Рус телендә урта(тулы) гомуми белем бирү мәктәпләре өчен татар теле һәм әдәбиятыннан үрнәк программалар " 1-11 нче сыйныфлар. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2011 нче ел. Ф.Ф.Харисов, Ч.М.Харисова, В,А,Гарипова авторлыгында. (программа федераль дәүләт белем стандартларына (ФГОС) нигезләнеп төзелгән).
10. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм Фән министрлыгының 2015/2016 нчы уку елында татар телен укыту үзенчәлекләре.Методик тәкъдимнәр.Казан.2014ел
11. СанПиН 2.4.2.2821-10 "Гомуми белем бирү учрежденияләрендә укыту өчен шартлар һәм укытуны оештыруга санитар-эпидемиологик таләпләр" (РФның баш дәүләт санитар табибының 189 нчы номерлы карары. 29.12.2010 ел)
12.Казан шәһәре Авиатөзелеш районы "134 нче татар-рус урта гомуми белем бирү мәктәбе" гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесенең 2015/2016 нчы уку елына уку-укыту планы**.**
12.Дәреслек: Татар теле: Рус телендә төп гомуми белем бирүче мәкт. 8 нче сыйныфы өчен д-лек (татар балалары өчен) /
Р. Ә.Асылгәрәева,Р.А. Юсупов, М. К. Зиннуров.- ( Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2011) нигезләнеп төзелде.

**Эш   программасы структурасы.**
Татар теленең эш программасы өч өлештән тора: аңлатма язуыннан, төп бүлекләрне, белем һәм күнекмәләрне үз эченә алган программаның эчтәлегеннән, укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләреннән

**Укыту фәненең уку планында тоткан урыны.** Укыту планында каралганча, татар теле  дәресләре өчен эш программасы атнага 3 сәгать исәбеннән елга 105 сәгатькә төзелде.

**Эш программасының эчтәлеге.**

**Татар теле укытуның максаты һәм бурычлары.**
Соңгы елларда республикада татар теленең куллану даирәсе киңәйде, иҗтимагый функциясе көчәйде. Милләтара мөнәсәбәтләрне якынлаштыручы, җайга салучы чара буларак та аның мөмкинлекләре үсте. Укучыларда лингвистик(тел), аралашу(коммуникатив), этнокультура өлкәсенә караган (культурологик) компетенцияләр булдыру татар теленә өйрәтүнең максатын тәшкил итә.
Лингвистик компетенция (укуыларның ана телелннән мәгълүматлылыгы) фонемалар, морфемалар, сүз ясалышы, сүзтезмәләр, җөмләләр, җөмлә кисәкләре, лексик һәм грамматик берәмлекләр, лингвистик анализны һ.б. үз эченә ала.
Аралашу (коммуникатив) компетенциясе ул – башкалар әйткәнне аңлау һәм үз фикереңне белдерү өчен тупланган белем, осталык, күнекмәләр җыелмасы; хәзерге татар теле нормаларына ия булу, сүз байлыгын, сөйләмнең грамматик ягын дөрес итеп үзләштерү; телдән һәм язма формада бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен булдыру һ.б.
Этнокультура өлкәсенә караган (культурологик) компетенция, ягъни телне милли-мәдәни яссылыкта үзләштерү ул – укучыларны сөйләмгә милли үзенчәлекләрне чагылдырган текстлар белән эшләү, тормыш-көнкүреш, гореф-гадәт үзенчәлекләрен, сынлы сәнгать әсәрләрен, халык авыз иҗаты үрнәкләрен белү, татар сөйләм этикетына ия булу.
Бурычлары :
1. Татар телен өйрәнүгә карата башлангыч сыйныфларда нигез салынган кызыксынуны көчәйтү, үз милләтеңә, телеңә хөрмәт белән карау, шулай ук татар теле аша башка милләт вәкилләренә, аларның рухи мирасына мәхәббәт хисе тәрбияләү.
2. Татар теленең барлык тармаклары буенча эзлекле рәвештә фәнни белем бирү.
3. Сөйләм эшчәнлеге төрләре буенча ныклы күнекмәләр булдыру. Туган телдә матур һәм дөрес аралашырга өйрәтү.
4. Телдән һәм язма сөйләм осталыгы һәм күнекмәләрен камилләштерү. Көндәлек тормышта татар теле мөмкинлекләреннән тулысынча файдалана белергә өйрәтү.
5. Туган тел аша өзлексез белем һәм тәҗрибә туплау.
6.Татар телен башка фәннәрдә белем алу чарасы буларак кулланырга өйрәтү күнекмәләрен булдыру.
7. Татар теле, аның төзелеше, кулланылышы турында мәгълүмат алу; татар әдәби теленең төп нормаларын һәм стилистик мөмкинлекләрен ачык күзаллау, аларны тиешенчә куллана белү; сүз байлыгын арттыру, сөйләмдә кулланыла торган грамматик чараларны төрләндерү.
8. Укучыларны даими рәвештә татар милли мәдәнияте мирасына тарту.
9. Татар теле дәресләрендә, белем бирү белән бергә, тәрбияви бурычларны онытмаска кирәк.
10. Телне өйрәнгәндә үзләштергән белем һәм күнекмәләрне гамәлдә дөрес куллана белү.
11. Укучыларның логик фикерләү сәләтен үстерү.
12. Дәреслек, өстәмә һәм белешмә әдәбият белән эш итү, уку, язу күнекмәләрен камилләштерү.

Рус мәктәпләрендә укучы татар балаларының күбрәк рус телендә аралашуларын һәм фәннәрнең рус телендә үзләштерелүен истә тотып, темаларны үткәндә, грамматик категорияләрне аңлатканда, татар теленә хас күренешләрне рус теле белән янәшә куеп (сопостовительная грамматика) аңлату нәтиҗәле.
Укучыларның гомуми грамоталылыгын тикшерү һәм үстерү өчен төрле характердагы диктантлар, шулай ук сүзлек байлыгын арттыру, бәйләнешле сөйләм үстерү, логик фикерләү дәрәҗәсен камилләштерү максатыннан сочинение һәм изложениеләр яздырыла.
Эш программасы тел белеме тармаклары арасында системалылык һәм эзлеклелек, фәннилек, аңлаешлылык принципларын истә тотып төзелде

**Яңа уку елы башына укучыларның белем, осталык һәм күнекмәләренә кыскача характеристика.**

**Фонетика:**

1. Сузык һәм тартык авазларның классификациясен, алардагы үзгәрешләрне белү. Сингармонизм законын, рәт һәм ирен гармониясе үзенчәлекләрен сөйләмдә дөрес куллану.
2. Татар телендә иҗек калыплары, сүзләрне дөрес басым белән әйтү. Тиешле интонация белән сөйләү.
3. Аваз һәм хәрефләрне аера белү. Алфавитны истә калдыру.
4. Сүзләргә фонетик анализ ясау.
5. Орфоэпик сүзлекләрдән файдалану.

**Лексика һәм фразеология:**

1. Татар теленең сүзлек составын килеп чыгуы, кулланылу өлкәсе һәм кулланылу дәрәҗәсе буенча бәяли белү.
2. Сүзләрне һәм фразеологизмнарны урынлы куллану, аларның мәгънәләренә аңлатма бирә белү. Синоним, омоним, антоним сүзләрне дөрес куллану.
3. Төрле типтагы сүзлекләрдән файдалана белү.

**Сүз төзелеше һәм сүз ясалышы:**

1.Сүзләрнең мәгънәле кисәкләренә аңлатма бирә белү. Тамырдаш сүзләр табу. Сүзләрне төзелеше һәм ясалышы буенча тикшерү.
2. Татар телендә сүзләрнең ясалыш ысулларын белү.

**Морфология:**

1. Сүз төркемнәрен лексик-грамматик мәгънәсе, морфологик һәм синтаксик билгеләре буенча аера һәм аларны таный белү. Морфологик анализ ясау.
2. Өйрәнелгән сүз төркемнәре белән җөмләләр һәм текстлар төзү. Сүз төркемнәренең төрле ысуллар белән ясалышын белү.

**Синтаксис:**

1. Җөмләнең баш кисәкләрен табып , аларның нинди сүз төркеме белән белдерелүен әйтү. Аергычны табып, аның сыйфат һәм сан белән белдерелүен күрсәтү.
2. Җыйнак һәм җәенке җөмләләрне телдән һәм язма сөйләмдә дөрес куллану.
3. Тиңдәш кисәкләрне билгеләү, алар янында тыныш билгеләрен дөрес куллану.
4. Эндәш сүзләрне иядән аеру, алар янында тыныш билгеләрен дөрес кую.
5. Җөмләгә синтаксик анализ ясау күнекмәләре булдыру(ия, хәбәр, аергыч, тиңдәш кисәкләрне күрсәтә белү).

**Сөйләм эшчәнлеге:**

1. Тыңлаучылар ачык күзалларлык итеп, яратып укыган әсәрдән берәр әдәби герой турында сөйләү.
2. Укучыларның, үз тәҗрибәләреннән чыгып, диалогик һәм монологик сөйләм оештыра белүе.
3. Эш кәгазьләреннән белдерү, котлау тексты язу.

4. Грамматик биремле контроль диктантлар, төрле типтагы диктантлар язу.
5. Рәсемгә карап, хикәя төзү.
6. Изложениеләр язу
7. Мөстәкыйль һәм ярдәмче сүз төркемнәрен кертеп төзелгән җөмләләрне тәрҗемә итү.

**8нче класс укучыларның белем дәрәҗәсенә таләпләр.**

1. Алдагы сыйныфларда алган белем һәм күнекмәләрне ныгыту.

**Гади җөмлә синтаксисы һәм пунктуациясе:**

1. Сүзтезмәләргә, гади җөмләләргә синтаксик анализ ясый белү.
2. Җөмләнең баш кисәкләрен, иярчен кисәкләрен табып , аларның нинди сүз төркеме белән белдерелүен әйтү .Ия белән хәбәр янында сызык кую очракларын белү.
3. Сүзтезмәне җөмләдән аера белү. Сүз төркеме белән җөмлә кисәген дөрес билгеләү.
4. Аерымланган җөмлә кисәкләре, эндәш һәм кереш сүзләр кергән җөмләләр төзү. Аерымланган хәлләр, аерымланган аныклагычлар, эндәш, кереш сүзләр янында тыныш билгеләрен куя белү.
5. Туры һәм кыек сөйләмне дөрес куллану, алар кергән җөмләләр төзү. Диолог, туры һәм кыек сөйләм янында тыныш билгеләрен куя белү.
6. Җөмләнең әйтү максаты ягыннан төрен, интонация, логик басым һәм сүз тәртибен белү. Җөмлә ахырында тыныш билгеләрен куя белү.
7. Тиңдәш кисәкләрне билгеләү, алар янында тыныш билгеләрен дөрес куллану.

**Сөйләм эшчәнлеге:**

1. Эш кәгазьләреннән әдәби әсәр героена адресланган хат язу, әдәби геройларга характеристика язарга өйрәнү.
2. Укучыларның, үз тәҗрибәләреннән чыгып, диалогик һәм монологик сөйләм оештыра белүе. Хикәяләр язу.
3. Грамматик биремле контроль диктантлар, төрле типтагы диктантлар язу
4. Сочинение элементлары булган изложениеләр язу
5. Татар телендәге сүз тәртибе үзенчәлекләрен чагылдырган кыска текстларны тәрҗемә итү күнегүләре үтәү.
6. Бирелгән план буенча сочинениеләр язу
7. Төрле сүзлекләрдән һәм белешмә характерындагы китаплардан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан урынлы файдалану

| чирекләр | Сәг.саны |
|---|---|
| 1ч | 27 |
| 2ч | 21 |
| 3ч | 30 |
| 4ч | 27 |
| Еллык | 105 |

**Практик өлеш** (белем һәм күнекмәләрен бәяләү формалары)

| | 1 чирек | 2 чирек | 3 чирек | 4 чирек | Еллык |
|---|---|---|---|---|---|
| | Сәгать саны | | | | |
| Дәрес | 27 | 21 | 30 | 27 | 105 |
| Теманы өйрәнү | 22 | 17 | 24 | 22 | 85 |
| Бәйләнешле сөйләм үстерү | 6 | 4 | 6 | 9 | 25 |
| Изложение | 1 | 1 | 1(к) | 2(1к) | 5(2к) |
| Диктант | 2(1к) | 2 | 1(к) | 2 | 7(2к) |
| Сочинение | 2 | 1 | 3(1к) | | 6(1к) |
| Тест | | 1(бел.к.эше) | | 1(арад.ат) | 2 |
| Дәрестә берникадәр вакыт биреп үткәрелә торган эшләр (15-20 минут) | | | | | |
| Сүзлек диктант | 2 | 1 | | 1 | 4 |
| Тест | 1 | 1 | 2 | 1 | 5 |
| Практик эш(тәрҗемә) | 2 | 1 | 3 | | 5 |
| Мөстәкыйль эш | 1 | | 4 | | 5 |

**Язма эшләрнең күләме һәм аларны бәяләү**

Укучыларның тел һәм сөйләм материалын үзләштерү дәрәҗәсен яки аларның гомуми грамоталылыгын диктант, изложение, сочинение яздырып тикшереп була; сорауларга язма рәвештә җавап алу да уңай нәтиҗә бирә. Сораулар укыган әсәр, аерым текст, рәсем яки караган фильмнар буенча тәкъдим ителә. Бу очракта язма эшнең күләме һәр сыйныфның изложение күләменнән артмый. Укытучы, эшне бәяләгәндә, түбәндәге таләпләрне истә тотарга тиеш: җавапның тулы, төгәл, дөрес 48 булуы, сөйләмнең стилистик яктан камиллеге, орфографик һәм пунк-туацион яктан грамоталылыгы.

**Сорауларга җавап язуны бәяләү:**

Барлык сорауларга да дөрес җавап бирелсә, «5» ле куела (1 сөйләм хатасы яки 1 пунктуацион хата булырга мөмкин).

Сорауларга дөрес җавап бирелсә, ләкин 2 сөйләм хатасы, 3 ор¬фографик, 2 пунктуацион хата яки 2 сорауга җавап язганда, төгәлсезлек җибәрелсә, «4» ле куела.

Язма эштә сорауларга җавап бирә белү күнекмәләре сизелсә, 3 сөй¬ләм хатасы, 4 орфографик, 5 пунктуацион хата булса, «3» ле куела.

Җавапларның яртысы дөрес булмаса, сөйләм хаталары 3 тән артса, 5 орфографик, 6 пунктуацион хатасы булса, «2» ле куела.

**Язма эшләрнең күләме**

| Сыйныфлар | Эш төре | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Сочинение | Диктант | Изложение | Барлыгы |
| 5 | 4(1) | 6(2) | 5(2) | 15(5) |
| 6 | 5(1) | 6(2) | 5(2) | 16(5) |
| 7 | 6(1) | 7(2) | 5(2) | 18(5) |
| 8 | 6(1) | 7(2) | 5(2) | 18(5) |
| 9 | 7(2) | 5(2) | 2(1) | 14(5) |
| 10 | 6(2) | 4(2) | 2(1) | 12(5) |
| 11 | 6(2) | 4(2) | 2(1) | 12(5) |

**Искәрмә.** Җәя эчендә контроль характердагы эшләр саны күрсәтелде.

**Диктантларның күләме һәм ал аларны бәяләү**

Диктант — укучының гомуми грамоталылыгын тикшерү өчен уз¬дырыла торган язма эшнең бертөре. Диктантлар өйрәтү һәм контроль төрләргә бүленә.

Өйрәтү диктантын бәяләү

Өйрәтү диктантлары берничә төрле була: сүзлек диктанты, искәртмәле, аңлатмалы, сайланма, иҗади, күрмә, хәтер, ирекле диктантлар.

Орфографик хатасы булмаса, «5» ле куела (1 пунктуацион хата булырга мөмкин).

1орфографик, 1 пунктуацион хатасы булса, «4» ле куела.

2орфографик, 2 пунктуацион хатасы булса, «3» ле куела.

5орфографик, 4—6 пунктуацион хатасы булса, «2» ле куела. Өйрәтү диктантлары 5—7 нче сыйныфларда ешрак яздырыла.

**Сүзлек диктантының күләме**

| Сыйныфлар | Сүзләр саны |
|---|---|
| 5 | 16—20 |
| 6 | 18—25 |
| 7 | 22—30 |
| 8 | 26—34 |
| 9 | 30—38 |

Сүзлек диктантына әйтелеше белән язылышы туры килмәгән сүзләр, гарәп - фарсы алынмалары кертелә.

**Сүзлек диктантын бәяләү**

Пөхтә итеп язылган, хатасы булмаган эшкә «5» **ле** куела.

1 орфографик хаталы эшкә **«4» ле** куела.

3 орфографик хаталы эшкә **«3» ле** куела.

5 орфографик хаталы эшкә **«2» ле** куела.

**Контроль диктантларның күләме һәм аларны бәяләү**

Алган белем һәм күнекмәләрне тикшерү өчен, контроль диктантлар елга ике тапкыр яздырыла.

Контроль диктантның күләме

| Сыйныфлар | Сүзләр саны | |
|---|---|---|
| | Уку елы башында | Уку елы ахырында |
| 5 | 50 | 50—60 |
| 6 | 55—60 | 60—70 |
| 7 | 65—80 | 75—90 |
| 8 | 85—100 | 95—110 |
| 9 | 105—120 | 115—125 |
| 10 | 120—130 | 125—135 |
| 11 | 130—140 | 135—145 |

Татар теле дәресләрендә укытучы укучыларның язу тизлегенә дә игътибар итәргә тиеш. Акрынрак язган укучылар белән аерым эшләргә кирәк. Бу эшне оештыру өчен, сүзләр һәм хәрефләрнең саны түбәндәгечә

| Сыйныф | Сүзләр саны | Хәрефләр саны |
| --- | --- | --- |
| 5 | 8—9 | 50—55 |
| 6 | 10—11 | 56—61 |
| 7 | 12—13 | 62—67 |
| 8 | 14—15 | 68—76 |
| 9 | 16—17 | 77—87 |

тәкъдим ителә.

Котроль диктант текстлары үз эченә өйрәнелгән тема яки темалар буенча орфограмма һәм пунктограммаларны (2—3 очрак) ала. Грамматик биремле диктант булганда, сүз саны киметелә дә ала. Контроль диктантта укучы тарафыннан төзәтүләр күп булса, билге бер баллга төшәргә мөмкин.

**Контроль диктантны бәяләү**

Эш пөхтә башкарылса, хатасы булмаса «5» ле куела (1 орфографик, 2 пунктуацион хата булырга мөмкин).

2 орфографик, 2 пунктуацион яки 1 орфографик, **4** пунктуацион хаталы эшкә **«4» ле** куела.

**4** орфографик, **4** пунктуацион яки 3 орфографик, 6 пунктуацион хаталы эшкә **«3» ле** куела.

6 орфографик, 5 пунктуацион яки 5 орфографик, 8 пунктуацион хаталы эшкә **«2» ле** куела.

**Изложениенең күләме һәм аны бәяләү**

Изложение яздыру өчен, матур әдәбият әсәрләреннән өзекләр, хикәяләр, аерым текстлар алына. Алар эчтәлеге һәм күләме ягыннан тиешле таләпләргә җавап бирергә, тәрбияви максатларны үз эченә алырга һәм бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен үстерү, камилләштерү юнәлешендә булырга тиеш. Изложение ярдәмендә укучының тема эчтәлеген ача белү осталыгы, лексик байлыгы, орфография, грамматика, пунктуация өлкәсенә караган грамоталылыгы тикшерелә. Бу вакытта яңа сүзләр һәм тәгъбирләрне аңлатырга, аларны тактага язып куярга кирәк.

Изложениене бәяләгәндә, фикерләрнең логик эзлеклелегенә, эчтәлекнең тулы, дөрес бирелүенә, язма сөйләм теленең камиллегенә, грамоталы. Изложение һәм сочинение өчен ике билге куела: беренчесе—эчтәлек һәм сөйләмне дөрес оештыра алуга, икенчесе — грамоталылыкка. итеп яза алу дәрәҗәсенә игътибар ителә

**Изложение текстынын**

| Сыйныф-лар | Уку елы башы | | Уку елы ахыры | |
| --- | --- | --- | --- | --- |
| | Тексттагы сүзләр саны | Язма күләме | Тексттагы сүзләр саны | Язма күләме |
| 5 | 70—110 | 55—70 | 110—140 | 70—85 |
| 6 | 140—160 | 85—95 | 160—190 | 95—105 |
| 7 | 190—230 | 105—115 | 230—270 | 115—125 |
| 8 | 270—310 | 125—130 | 310—350 | 130—135 |
| 9 | 350—370 | 135—140 | 370—390 | 140—145 |

**Изложениене бәяләү**

Тема тулысынча ачылган, эчтәлеге һәм стиль бердәмлеге сакланган эшкә «**5**» **ле** куела (1 орфографик, 2 пунктуацион яки 2 грамматик хатасы булырга мөмкин).

Текстның эчтәлеге темага, нигездә, туры килсә, фикерне белдерүдә зур булмаган ялгышлар җибәрелсә, 1—2 фактик, 1—2 техник хатасы булса, 2 орфографик, 2—3 пунктуацион, 1 грамматик хатасы булган эшкә **«4» ле** куела.

Язмада эчтәлек эзлекле бирелмәсә, стиль бердәмлеге сакланмаса, 3 фактик, 2—3 техник хатасы булса, 3 орфографик, 4 пунктуацион, 2 грамматик хатасы булган эшкә **«3» ле** куела.

Эзлеклелек, стиль бердәмлеге сакланмаса, язма эш планга туры килмәсә, фактик һәм техник хаталары күп булса, орфографик хаталарның саны 4 тән артса,пуктуацион хаталарның саны 5тән, грамматик хаталар саны 3 тән артса**,"2"ле** куела.

**Сочинениеләрне бәяләү нормалары һәм критерийлары**

Иҗади эшнең бер төре буларак, сочинение — укучының язма рәвештә үти торган эше. Ул бәйләнешле сөйләм үстерү күнекмәләре булдыруда зур əһәмияткә ия.

Тәкъдим ителгән темага эзлекле язылган, эчтәлеге тулысынча ачылган,
эшкә **«5» ле** куела. (Бер орфографик яисә ике пунктуацион (грамматик) хата булырга мөмкин.)

Тәкъдим ителгән темага эзлекле язылган, ләкин 2-3 эчтәлек ялгышы, 2-3 орфографик, 2-3 пунктуацион хатасы булса, **«4» ле** куела.

Тәкъдим ителгән темага өлешчә эзлекле язылган, эчтәлеге тулысынча ачылмаган, 4-5 орфографик, 4-5 пунктуацион һәм грамматик хатасы булса, **«3»** ле куела.

Тәкъдим ителгән темага эзлекле язылмаган һәм эчтәлеге ачылмаган, 6 дан артык орфографик, 6 дан артык пунктуацион һәм грамматик хатасы булса, **«2»** ле куела.

**Программа материалының эчтәлеге.**

| № | Төп темалар | Сәг. | Темага караган төп төшенчәләр. |
|---|---|---|---|
| 1 | 5-7 сыйныфларда үткәннәрне кабатлау. | 4 | сүз ясалышы, сүз төзелеше, сүз төркемнәре, фигыль, фигыль юнәлешләре, җөмләдә сүзләр тәртибе; |
| 2 | Синтаксис турында төшенчә | 3 | синтаксис турында төшенчә, синтаксик берәмлекләр; |
| 3 | Җөмләдә сүзләр бәйләнеше. Сүзтезмә. | 4 | җөмләдә сүзләр бәйләнеше,тезүле бәйләнеш, ияртүле бәйләнеш, сүзтезмә, рус һәм татар телләрендә сүзләр бәйләнеше; |
| 4 | Сүз тәртибе. | 5 | Уңай һәм кире сүз тәртибе. Татар һәм рус телләрендә сүзләрнең урнашу тәртибе үзенчәлекләре. |
| 5 | Гади җөмлә төрләре. | 1 | Җөмлә турында кабатлау. |
| 6 | Әйтү максаты ягыннан җөмлә төрләре. | 4 | Хикәя, сорау, боеру , тойгылы җөмләләр, алар янында тыныш билгеләре. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 7 | Җөмлә кисәкләре. Гомуми мәгълүмат. | 2 | Җөмлә кисәкләре турында мәгълүмат |
| 8 | Баш кисәкләр | 3 | җөмлә кисәкләре, ия һәм аның белдерелүе, хәбәр һәм аның белдерелүе, кушма хәбәр һәм аның белдерелүе, ия белән хәбәр арасында сызык; |
| 9 | Җөмләнең иярчен кисәкләре | 27 | аергыч һәм аның белдерелүе, аергыч белән аерылмыш арасында бәйләнеш; тәмамлык һәм аның белдерелүе,туры һәм кыек тәмамлыклар; хәл һәм аның төрләре: урын хәле, вакыт хәле, рәвеш хәле, күләм хәле, сәбәп хәле, максат хәле, шарт хәл, кире хәл; аерымланган хәлләр һәм алар янында тыныш билгеләре, төрле хәлләрнең аерымлануы; аныклагыч; аерымланган аныклагычлар, алар янында тыныш билгеләре, |
| 10 | Җөмләнең модаль кисәкләре | 2 | эндәш сүзләр һәм алар янында тыныш билгеләре; кереш сүзләр һәм алар янында тыныш билгеләре; кереш җөмләләр  һәм алар янында тыныш билгеләре; |
| 11 | Җөмләнең тиңдәш кисәкләре | 6 | тиңдәш кисәкләр, алар янында бәйләүче чаралар, тиңдәш кисәкләр һәм янында тыныш билгеләре; тиңдәш кисәкләр янында гомумиләштерүче сүзләр; |
| 12 | Модаль кисәкләр | 2 | сүзләрнең уңай һәм кире тәртибе, логик басым; |
| 13 | Бер составлы җөмләләр | 2 | бер составлы җөмләләр: исем җөмлә, фигыль җөмлә, сүз җөмлә; |
| 14 | Тулы һәм ким җөмләләр. | 8 | тулы һәм ким җөмләләр турында төшенчә; |
| 15 | Раслау һәм инкарь җөмләләр | 3 | раслау һәм инкарь җөмләләр, раслау һәм инкарь җөмләләрнең кулланлышы; |
| 16 | | | |
| 17 | Гомумиләштереп кабатлау. | 5 | Гади җөмлә синтаксисын кабатлау, синтаксик анализ ясау. |
| 18 | Бәйләнешле сөйләм телен үстерү. | 25 | |
| | Барлыгы | 105 | |

**Укыту-методик комплекты.**

1. ”Рус телендә урта(тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә татар телен һәм әдәбиятын укыту программасы” 1-11 нче сыйныфлар. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән, Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2011нче ел
2. 8 нчы сыйныфта татар теле дәреслеге. (Р.Ә. Асылгәрәева, Р.А. Юсупов, М.К. Зиннуров. Казан, “Татарстан китап” нәшрияты, 2011нче ел)
3. Татар теле морфологиясе. /Ф.М. Хисамова. - Казан, “Мәгариф” , 2005.
4. Хәзерге татар әдәби теле. / Ф.С. Сафиуллина, М.З.Зәкиев.- Казан, “Мәгариф”нәшрияты , 1994нче ел.
5. Урта мәктәп һәм гимназияләрдә татар телен укыту методикасы. / Ф.С.Вәлиева, Г.Ф. Саттаров. – Казан: “Раннур”, 2000нче ел.
6. “Диктантлар җыентыгы”(5-11 нче сыйныфлар өчен) З.Н.Хәбибуллина, Г.Ш.Нәбиуллина. Казан ”Мәгариф” нәшрияты, 2004нче ел.
7. “Мәгариф” журналы,”Фән һәм мәктәп”
8 . “Хикмәтле дә, бизәкле дә туган тел” Ф.С.Сафиуллина, Г.Б.Ибраһимов. Казан”Мәгариф” нәшрияты, 2003нче ел.
9. Сафиуллина Ф.С. Хәзерге татар әдәби теле. Югары һәм урта уку йортлары өчен дәреслек. Казан: Мәгариф, 2006.
10.Максимов Н.В. Татар теленнән тестлар. Казан: Мәгариф,2002.
11.Гыймадиева Н.С,Бонавиева Р.А.Контроль дитантлар һәм изложениеләр(5-11нче сыйныфлар өчен).-Казан:Мәгариф,2004.

**Укытучы өчен методик әдәбият**

1.“Мәгариф” журналлары, “Фән һәм мәктәп”, “Мәгърифәт”, “Ачык дәрес” газеталары.
2Хисамова Ф.М. Татар теле морфологиясе, Казан, “Мәгариф” ншәрияты, 2005 ел.
3.Ф. Ф. Харисов, Ч. М. Харисова. Татар теле. Кагыйдәләр җыентыгы. Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2007 ел.
4.Сүзлекләр: амонимнар, синонимнар, антонимнар, орфографик, татарча-русча, русча-татарча, татар теленең аңлатмалы сүзлеге, 3 томда.
5.Гыймадиева Н.С.,Галләмова Р.В.Татар теле:Кагыйдәләр җыентыгы.Анализ үрнәкләре.-Казан:Гыйлем, 2013.
6.Максимов Н.В., Шәйхразиева З.В.Таблицалар һәм схемалар.-Казан,2004
7.Фатыйхова Р.Н.Татар теленнән диктантлар, контроль эшләр, тестлар.-Казан”Гыйлем”нәшрияты,2009.
8.Шәмсетдинова Р.Р.Татар теле.Күнегүләр.Анализ үрнәкләре, Тестлар.-Казан”Татарстан китап”нәшрияты,2007.
9.Хәбибуллина,М.А.Вәлиуллин,Х.Г.Фәрдиева.5-11 сыйныфлар өчен язма эшләр.-Казан,2003.
10.Татар теленнән кагыйдәләр җыентыгы.-Казан,2003.
11. Хәбибуллина З.Н.,Гыйләҗев И.Г-Казан “Мәгариф”,1994.
12.Абдуллина Р.С.Хәзерге татар теленең орфографиясе һәм орфоэпиясе.-Казан:”Мәгариф”,2009.

**Мәгълүмат бирү чыганаклары**

http://www.mon.gov.ru РФ Мәгариф һәм фән министрлыгы
http://www.ed.gov.ru Белем бирү буенча федераль агентлык
http://www.fasi.gov.ru Фән һәм инновацияләр буенча федераль агентлык
http://www.obrnadzor.gov.ru Рособрнадзор
http://www.apkppro.ru РФ мәгариф хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү һәм профессиональ әзерләү академиясе
http://www.lexed.ru Федеральный центр образовательного законодательства
http://www.rustest.ruФедераль тест үткәрүүзәге
http://www. tatedu.ru ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы

http://www.edu. kzn.ru  ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы Белем полрталы
http://www.mon.tatar.ru
http://pedsovet.org  Бөтенроссия интернет-педкиңәшмәсе
http://www.bytik.ru Мәгариф системасында яңа технологияләр куллану – халыкара конференция
http://www.shoolexpo.ru
http://www.it-n.ru
http://. belem.ru
http://. tatar.ruТР  рәсми серверы
http://. tatcenter.ruТР мәгълүмати – аналитик порталы
http://. Tat. Tatar - inform.ru   ТР мәгълүмат агентлыгы
http://. intertat.ruТР электрон газетасы
http://. vatantat.ru  “Ватаным Татарстан” газетасы
http://. Tatar - kongres.ru  Бөтендөнья татар конгрессы
http://. xat.ru  Татар хат алышу хезмәте
http://. suzlek.ruon- line  русча сүзлеге
http://. Abaga.h16.ru  “Абага чәчәге” олимпиада
http://. Tugan-tel.at.ru     Шрифтлар  һәм IT- технологияләр
http://. Kitapxane.at.ru    татар телендәге әдәби әсәрләр китапханәсе
http://. Tatar.com.ru    татар теле сүзлекләр һәм үзөйрәткечләр
http://. Tatarca.boom.ru    татарча текстлар
http://. tataroved.ru   Татар тарихы: төрки – татар дөньясы
http://. selet.ru  “Сәләт” яшьләр үзәге

**Татар теленнән еллык календарь- тематик план. 8нче сыйныф.105 сәг.**

| № | Дәрес темасы | Тикшерү төре | Көтелгән нәтиҗә | Үтәлү вакыты | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | План | Факт |
| **I чирек-27 сәг.** | | | | | |
| **1. 5-7нче сыйныфларда үткәннәрне кабатлау (6 сәг)** | | | | | |
| 1 | Татар теле турында әңгәмә | | Х. Туфанның "Туган тел" шигырен укып фикер алышу. Туган тел турында күбрәк мәгълүмат алу. Туган тел, аны тарихы, кеше тормышындагы ролен таный алу. | 1.09 | |
| 2 | Авазлар темасын кабатлау | | Авазлар.Сузык һә тартык авазлар.Яңгырау һәм саңгырау тартыклар.Сингорманизм турыда булган белемнәрен ныгыту. Күнегүләр өстендә эшли белү. | 2.09 | |
| 3 | Сүз ясалышы һәм төзелеше бүлеген кабатлау. | | Сүз ясалышы һәм төзелешен, тамырдаш сүзләрне искә төшерү; Сүзләрне төзелешләре ягыннан тикшерү. Тамыр һәм кушымчаларны искә төшерү. Кушымчаларның төрләрен истә калдыру; Сүзләрне тамыр һәм кушычаларга таркату өстендә эш. Биремнәр үтәү, тамыр кушымчаларны аера белү. Дәреслек б-н эшләү,күрсәтмә материаллардан файдалану | 5.09 | |
| 4 | Морфология бүлеген кабатлау | | Мөстәкыйль сүз төркемнәре, аларның кулланышы, мәгънәсе .Исем, сыйфат ,Фигыль, алмашлык, сан, рәвеш, ымлыклар һәм аваз иярtемнәрен кабатлау.Күнегүләр үтәү,белемнәрне ныгыту өстендә эш. | 8.09 | |
| 5 | Синтаксис бүлеген кабатлау | | Ярдәмлек сүз төркемнәреен кабатлау.Ярдәмлек сүз төркемнәрен сөйләмдә дөрес куллана белү Теркәгеч, бәйлек, кисәкчәләр, аларның роле һәм кулланышын ныгыту | 9.09 | |
| 6 | **Керү контроль эше э((биремле диктант)** | Диктант | Сүз төркемнәре темасына диктант язу:"Ташлар һәм сәламәтлек".Орфографик һәм пунктуацион күнекмәләрне куллану. | 12.09 | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| **2. Гади җөмлә синтаксисы**<br>**2.1. Синтаксис буенча гомуми мәгълүмат (3 сәг.)** | | | | | |
| 7 | Синтаксис һәм пунктуация турында гомуми мәгълүмат. Хаталар өстендә эш. | | Синтаксис һәм пунктуация турында гомуми мәгълүмат.Күнегүләр үтәү. | 15.09 | |
| 8 | Синтаксик берәмлекләр турында төшенчә | | Синтаксис буенча гомуми мәгълүмат, аның өйрәнү объекты. Материалны ныгыту өстендә практик биремнәр, күнегүләр үтәү. | 16.09 | |
| 9 | Гади һәм кушма җөмләләр. | | Гади һәм кушма җөмләләр .Алар арасында аерма. Куллану үзенчәлекләре. Материалны ныгыту өстендә практик биремнәр, күнегүләр үтәү. | 19.09 | |
| **Җөмләдә сүзләр бәйләнеше.Сүзтезмә (4 сәг.)** | | | | | |
| 10 | Җөмләдә сүзләр бәйләнеше.тезүле бәйләнеш | | Җөмләдә сүзләр бәйләнеше: тезүле һәм ияртүле бәйләнеш, аларны белдерә торган тел чаралары. Рус теле белән чагыштыру һәм нәтиҗә чыгару. Материалны ныгыту өстендә практик биремнәр, күнегүләр үтәү. | 22.09 | |
| 11 | Сүз һәм җөмлә. | Тәрҗемә эше | Сүз һәм җөмлә.Алар арасында аерма. Куллану үзенчәлекләре. Материалны ныгыту өстендә практик биремнәр, күнегүләр үтәү. | 23.09 | |
| 12 | Тезүле һәм ияртүле бәйләнеш | | тезүле һәм ияртүле бәйләнеш, аларны белдерә торган тел чаралары, аларның аермалы яклары, кулланылыш үзенчәлекләре Рус теле белән чагыштыру һәм нәтиҗә чыгару. | 26.09 | |
| 13 | Сүзтезмә.Сүзлек диктант | Сүзлек диктанты | Сүзтезмәдә ияртүче һәм иярүче кисәкләр.Татар телендә сүзтезмәләрнең төрләре Рус теле белән чагыштыру һәм нәтиҗә чыгару. Сүзтезмәләрдә иярүче һәм ияртүче кисәкне таба белү, сорау куярга өйрәнү | 29.09 | |
